■ Йәшләргә нәсихәт

# АГАЧ ҺӘМ УРМАННЫ СӨЮ

Мөхәммәт ГАЛЛЯМОВ,
"Ихлас" мәчете имам-хатыйбы,
медицина фәннәре кандидаты.

***Бөек динебез, кешелек җәмгыятен бөтен ихтыяҗлары белән эченә алган бер дин. Белеүебезчә, Ислам дине көн-дәлек тормышыбызның һәр мизгелен, һәр өлешен яктыртучы, бу дөньяда, безне бәхетле итәр өчен һәм дә мәңгелек галәмгә, яки ахирәтебез өчен дә безне хәзерлекле булуыбызны нәсихәт итә.***

Дөреслектә, кешелек җәмгыятенең ихтыяҗына яраган һәрнәрсәләр тирә-ягыбызны уратып алган. Бу караштан, Раббыбыз Аллаһ тарафыннан бар ителгән нәрсәләрнең һәр төрлесе, кимчелексез бер шәкелдә уртага куелган.

Аеруча, агач һәм аны үстерүнең мөһимлеге, чүпле һәм такыр җирләрдә яшеллеге, урманлыгы булган чәчәкле бер өлкә итүне, динебез Ислам идея-хыял итеп йөрәкләребезгә салган. Нәкъ хәдис шәрифтә бәян ителгәнчә, гыйлем алу өчен бишектән ләхеткә кадәр бер гомер кирәк булгандай, урманга да бишектән ләхеткә кадәр мохтаҗ булуыбыз, ихтыяҗлыгыбыз көн кебек ачыктыр.

Һәр ел "Урманчылык атнасы" һәм "Бөтендөнья урманчылык көне" кебек сәбәпләргә таянып, өлкәбезне тагы да гөлчәчәкле бер өлкә итү максатында, урман байлыкларыбызны саклау ысуллары хакында сөйлибез, язабыз һәм аңлашабыз. Әмма шунысын да яхшы төшеник ки: бөек динебез бәхетле сәгадәтебез хакына булган эшләребездән, агач һәм урманга игътибарны елына бер яисә берничә көн түгел, бәлки, гомер буена, аны кешелек хәятеннән бер генә көнгә дә аермыйча, кыяматкә кадәр гөрләп-шаулап торганын ният вә максат иттерә. Сөекле пәйгамбәребезнең бу мәсьәләгә әһәмият бирүе дә, барчабызга да кыйммәтле бер нәсихәттер. Аллаһ Рәсүле (сгв) шулай боермактадыр: "Кыямәт кубарылачак заман булса да, кулыгызда булган бер хөрмә ботагын җиргә тыгу мөмкинлеге булса, һич тукталып калмагыз, аны хәзер үк утыртыгыз", - диде. Күрәсез, динебезнең агачка, урманга һәм, гомумән, яшеллеккә биргән әһәмиятен моннан тагы да ачыграк итеп аңлату чарасы юктыр. Хәтта гомеренең көзенә кадәр яшәгән кешенең кулында җиргә утыртырлык бер ботак булса да. Олуг пәйгамбәребез: "Ташла ул кулындагыны, намаз кыл, тәсбих тарт, тәүбә ит, хәер бир", - димәгән, бер агач утыртудан да тагы да саваплырак юл күрсәтмәгән.

Пәйгамбәребез хәзрәте Мөхәммәт (с.г.в.) дөньялыкта гомер кичергән вакытта башкарылган хәерле эшләрнең бәгъзеләре өчен, кеше үлгәннән соң да Аллаһ каршында аның дәрәҗәсен арттырачагын бәян иткән. Бу гамәлләрнең берсе - җимешлеме-җимешсезме булуына карамастан агач утыртудыр. Аллаһ илчесенең бу үгет-нәсихштләренә караганда, утыртылган агачның җимешләреннән вә күләгәсеннән кешеләр һәм башка җан ияләре рәхәт күрсәләр, аны утыртучының савап дәфтәре ябылмаячак. Үзе үлеп китсә дә, Аллаһ каршындагы дәрәҗәсе даими рәвештә күтәреләчәктер. Рәсүлюллаһның бу ачыкламаларында бөек динебезнең агач үстерү һәм аны тәрбияләүгә бирелгән әһәмияте никадәр ачык күренә.

Гасырлар - дәверләр буенча бөтен милләтләрдә агач һәм урман мәсьәләсенә әһәмият бирелгән, көч салынган. Бу үзенчәлекле кырыс холыклы заман урман мәсьәләсенә игътибарыбызны тагы да ныграк җәлеп иттерде. Әйтергә кирәк, икътисадый күтәрелү чаралары янында агач җитештерү вә урманнарын саклау юнәлешендә дә бик җитди хезмәтләр вә казанышлар күрсәтелде. Хәзерге көндә агачның һәм урманның әһәмиятен аңламаган, аңа булган ихтыяҗыбызны күрмәгән һичбер өлкә калмады. Агач һәм урманны җаны кебек саклаган, аны бала кебек караган илләр бар. Хәтта чүлләрдә - агачка карата җайсыз тәбигать шартларында, ком дәрьяларында, тауларда бакчалар һәм гөлчәчәк аланнары, сәхрәләр мәйданга китергән милләтләрнең булуы дөнъя тарихында күргәнебез бар. Дөреслектә бу юнәлеш тагы да мөкәммәл шәкелдә безнең юлыбыз булырга тиеш. Чөнки без - агач үстерүне үрнәк итеп күрсәткән, ә инде бер агач та үстермәүне гөнаһ итеп санаган дин Исламның, хәзрәте Мөхәммәд Мостафаның өммәтләребез.

Агач һәм урман - һәр өлкәнең иң саф мохите, иң гүзәл хәзинәседер, иң кыйммәтле чыганагы, иң игелекле бакчасыдыр. Анда хозур-рәхәтлек тойгылар белән хисләнгән бер нечкә рух, бәгырьләрне иркәләүче бер илаһи низам бар. Башка һичбер нәрсә белән чагыштырмаслык, кешенең матди вә мәгънәви һавасы өчен әйтеп бетерә алмаслык кирәкле шифа-дәвалар бар.

Агач кәлимәсе телебезгә кергәннән бирле, ул - балаларыбызның бишеге, өйләребезнең - ишеге, шулпабызның кашыгы учагыбызның яктысыдыр. Дөньяга күзебезне ачканнан алып ахирәт сәфәренә киткәнгә кадәр мохтаҗ булган барлыгыбыздыр.



Һич әөбһәсез, агач һәм урман хәтта XXI гасырга да киң яктылык биргән нурдыр. Бу яктылык ялыз бер учактан күтәрелгән яктылык түгел, бәлки калебләрнең вә күңелләрнең түрен җылыткан бер яктылыктыр, фазыйләт вә мәгърифәт китерүче бер нурдыр.

Агач ул - һәр таңда утырып укыган гәзитебез, белемебезне арттыру өчен укыган китабыбыз. Бу таңнар, бу иртәләрдә мәктәпкә озаткан балаларыбызның сумкасындагы дәфтәредер, каләмедер. Өебездә баш очыбызга олуг бер хөрмәт белән урнаштырган мөкатдәс аять-җәлиләләр язылган кәгазьләр.

Агач утыртуны гыйбадәт итеп санаган мөкатдәс динебезнең агачларны һәм урманнарны кыргыйларча харап итүчеләргә хөкеме, шикләнмәгез, җәмгать, үлем җәзасы түгел. Ләкин ике аршин туфрак, җир өчен урманнарны ут ягып яндыруга кадәр барып җиткән кешеләр, бөек Раббыбыз каршында бу җинаятьләренең хисабын биргәндә бик җәфаланачаклар, газап кичерәчәкләр. Рәсми булган мәгълүматларга караганда, илебездә ут чыгу аркасында янган урманнарның 99 проценты кеше кулыннан чыккан янгындыр. Ягъни бу ваемсыз вә куркыныч җинаятьләрне җир кешеләре, безнең ватандашларыбыз да эшлиләр. Хәтта сугыш шартларында да гаскәр башлыгына бирелгән әмерләр арасында хатыннарны, балаларны һәм картларны үтермәгез, диеп катгый рә-вештә тыелган. Шулай ук агачларның сәбәпсез вә чарасыз киселеп әрәм ителүе дә шулай аянычлы. Уңдырышлы җир-ләрне саклаучы урманнарга игътибар иттерүче инсан һәм урманны корыткан кеше арасындагы капма-каршылык ни кадәр зур!

Ягъни бөек динебез хәтта дошман һәлакәтендә калган җимеш агачларын юк итмәскә өнди. Инде моңа юл куючылар булса, бу - үзләрен милли хурлыкка китерүче бер куркыныч хәлдер, никадәр үкенечтер, никадәр гөнаһтыр.

Халкыбыз арасында киң таралган "Яшь агач кисәр - башкисәр" әйтеме дә агач һәм урманга булган мәхәббәтне, урман дошманнарына нәфрәтен күрсәтә.

"Яшеллек күрмәгән күзләр төрле төсләр, буяулар күрү ләззәтеннән мәхрүмдер", - диелгән.

Үз йортында дик кардәшенә кул күтәрүче никадәр гөнаһлы булса, милли иминлегебез, икътисадыбызның нигезе булган урманнарыбызны утта яндыру, һәлак итү дә - җинаятьтер, гөнаһтыр.

Кем җәннәт ватанын коры такырлык, чүплек хәлендә калдырса, йөрәгендә тамчы кадәр Аллаһ һәм ватанны сөю тойгысы булган кеше дә моңа риза булмас.

Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Йомадиәл ахыр 2010 миләди йыл**
**1431 һижри йыл.**

| Йомадиәл ахыр | Аҙна көндәре | Май | Иртәнге намаҙ | Ҡояш ҡалҡа | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. намаҙы | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шәмбе | 15 | 4.40 | 6.10 | 14.30 | 20.46 | 22.16 | 23.46 |
| 2 | Йәкшәмбе | 16 | 4.39 | 6.09 | 14.30 | 20.48 | 22.18 | 23.48 |
| 3 | Дүшәмбе | 17 | 4.37 | 6.07 | 14.30 | 20.50 | 22.20 | 23.50 |
| 4 | Шишәмбе | 18 | 4.35 | 6.05 | 14.30 | 20.51 | 22.21 | 23.51 |
| 5 | Шаршамбы | 19 | 4.34 | 6.04 | 14.30 | 20.53 | 22.23 | 23.53 |
| 6 | Кесе йома | 20 | 4.32 | 6.02 | 14.30 | 20.55 | 22.25 | 23.55 |
| 7 | Йома | 21 | 4.31 | 6.01 | 14.30 | 20.57 | 22.27 | 23.57 |
| 8 | Шәмбе | 22 | 4.29 | 5.59 | 14.30 | 20.58 | 22.28 | 23.58 |
| 9 | Йәкшәмбе | 23 | 4.28 | 5.58 | 14.30 | 20.59 | 22.29 | 23.59 |
| 10 | Дүшәмбе | 24 | 4.26 | 5.56 | 14.30 | 21.01 | 22.31 | 00.01 |
| 11 | Шишәмбе | 25 | 4.25 | 5.55 | 14.30 | 21.03 | 22.33 | 00.03 |
| 12 | Шаршамбы | 26 | 4.24 | 5.54 | 14.30 | 21.04 | 22.34 | 00.04 |
| 13 | Кесе йома | 27 | 4.22 | 5.52 | 14.30 | 21.05 | 22.35 | 00.05 |
| 14 | Йома | 28 | 4.21 | 5.51 | 14.30 | 21.07 | 22.37 | 00.07 |
| 15 | Шәмбе | 29 | 4.20 | 5.50 | 14.30 | 21.08 | 22.38 | 00.08 |
| 16 | Йәкшәмбе | 30 | 4.19 | 5.49 | 14.30 | 21.10 | 22.40 | 00.10 |
| 17 | Дүшәмбе | 31 | 4.18 | 5.48 | 14.30 | 21.11 | 22.41 | 00.11 |
| 18 | Шишәмбе | 1 | 4.17 | 5.47 | 14.30 | 21.12 | 22.42 | 00.12 |
| 19 | Шаршамбы | 2 | 4.16 | 5.46 | 14.30 | 21.14 | 22.44 | 00.14 |
| 20 | Кесе йома | 3 | 4.15 | 5.45 | 14.30 | 21.15 | 22.45 | 00.15 |
| 21 | Йома | 4 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.16 | 22.46 | 00.16 |
| 22 | Шәмбе | 5 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.17 | 22.47 | 00.17 |
| 23 | Йәкшәмбе | 6 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.18 | 22.48 | 00.18 |
| 24 | Дүшәмбе | 7 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.19 | 22.49 | 00.19 |
| 25 | Шишәмбе | 8 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.20 | 22.50 | 00.20 |
| 26 | Шаршамбы | 9 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.21 | 22.51 | 00.21 |
| 27 | Кесе йома | 10 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.22 |
| 28 | Йома | 11 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 29 | Шәмбе | 12 | 4.09 | 5.39 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 1 | Йәкшәмбе | 13 | 4.09 | 5.39 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |

# Пәйгамбәребезнең соңгы вәгазе

***(Азагы. Башы № 4).***

Кешеләр! Бүген шайтан сезнең бу туфракларыгызда яңадан үзенең тәэсир көчен мәңгегә югалтты. Ләкин мин тыйган, үзегез өчен әһәмиятсез булып күренгән эшләрдә аңа иярсәгез, бу эшегез аны шатландырачак кына. Динегезне, иманыгызны саклау өчен болардан да тыелыгыз.

Кешеләр! Хатыннарның хакларын хаклауны онытмагыз. Мин сезгә бу эштә Раббил Хактан куркырга киңәш итәм. Сез хатыннарыгызны Аллаһ әманәте белән алдыгыз. Аларның намуслары һәм гыйффәтләре хакында Аллаһ Тәгаләгә сүз биреп аларны хәләл иттегез. Сезнең хатыннарга карата хакларыгыз, аларның сезгә хаклары бар. Сезнең аларга карата хакларыгыз - хатыннарыгызның гаилә учагын сезгә ошамаган кешеләрдән саклауда. Әгәр сез теләмәгән берәү гаилә учагыгызга якын килсә, аларны төрткәләп куып җибәрегез. Хатыннарның сезгә карата хаклары, алар яшәгән җир үзенчәлекләренә карап, кирәк булган кием-салым һәм азык белән тәэмин итүегездер.

Мөэминнәр! Сезгә бер әманәт калдырам. Ул әманәтне нык сакласагыз, юлыгызны һич югалтмассыз. Ул әманәт - Раббил Гыйззә вә Тәгаләнең Бөек китабы Коръән Кәримдер.

Мөэминнәр! Сүземне тыңлагыз һәм һичкайчан да онытмагыз. Мөселман - мөселманның кардәшедер. Димәк, барлык мөселманнар үзара туганнардыр. Кардәшеңнең хакына керү беркемгә дә дөрес түгел. Кем дә булса кешедән әйбер ала икән, ул алган әйбере бирүченең үз кулы белән биргән әйбере булсын.

Кешеләр! Раббыгыз бердер. Атагыз да бердер. Сез барыгыз да Әдәм (г.с.) балалары. Ул исә үзе туфрактан яратылган. Аллаһ янында сезнең иң хөрмәтлеләрегез - Аңа кадер-хөрмәт күрсәтүчеләрегездер. Гарәпнең гарәп булмаганнарыгыздан Аллаһы Тәгаләне хөрмәтләүдә бернинди өстенлеге юк...

***Мөселман кардәшләр! Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.)нең соңгы вәгазеннән күренүенчә, без бер-беребезгә карендәш булабыз. Шулай булгач, без бер-беребезгә карата туганнарча мөгамәләдә яшәргә тиешбез. Әгәр дә без изгелек итсәк, безгә дә изгелек итәрләр, яманлык кылсак, шуны күрербез. Шуны онытмаска кирәк: гөнаһ нигъмәтнең үзгәрүенә сәбәпче булып тора. Фани дөньяда ничек яшәсәк, ахирәттә шуның әҗерен алачакбыз. Мизан мәйданына җыелганда, гамәл дәфтәрләребез уң яктан бирелгәннәрдән булсак икән, инша Аллаһ.***